ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**БОЕРЫК** **БОЕРЫК**

25.06.2015 Казан ш. № 259-к

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе ведомствасы бүләкләре турында

“Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль закон, “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 10 мартындагы № 202 карары белән расланган нигезләмәнең 5 бүлегендәге 5.2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе карамагындагы дәүләт ветеринария учреждениеләре хезмәткәрләрен, хезмәт эшчәнлегендәге югары казанышлары өчен, башка оешмалар (учреждениеләр) хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләнгән бурычларны хәл итүдә ярдәм итүче затларны бүләкләү системасын камилләштерү максаты белән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең түбүндәге ведомство бүләкләрен оештырырга:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Мактау грамотасы;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгының Рәхмәт хаты.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең Мактау грамотасы турында нигезләмә (1 нче кушымта)4

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгының Рәхмәт хаты турында нигезләмә (2 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү формасын (3 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең ведомство бүләге белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алу журналы формасын (4 нче кушымта).

3. Хокук бүлеге башлыгы А.А.Исмәгыйлевка әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрерүне һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгаруын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең ветеринария эшен оештыру бүлеге башлыгы И. А. Сөләймановка:

- әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең Мактау грамотасы турында Нигезләмәне, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгының Рәхмәт хаты турында Нигезләмәне, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү формасын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә буйсынган дәүләт ветеринария учреждениеләренә җибәрергә.

5. Бүләкләү өчен материаллар әзерләү, ведомство бүләкләрен исәпкә алу һәм бирү эшен оештыруны, шулай ук бүләкләү документларын рәсмиләштерү буенча методик җитәкчелекне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә йөкләргә.

6. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе башлыгы –
Татарстан Республикасы
Баш дәүләт ветеринария инспекторы А.Г.Хисаметдинов

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең
10.07.2015 № 286-к боерыгына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең мактау грамотасы турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Мактау грамотасы (алга таба - Мактау грамотасы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең ведомство бүләге булып тора.

Мактау грамотасы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба - Ветеринария идарәсе) хезмәткәрләре, дәүләт ветеринария учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре, Татарстан Республикасының башка министрлыклары һәм ведомстволары хезмәткәрләре, шулай ук ветеринария идарәсенә йөкләнгән бурычларны хәл итүдә ярдәм итүче оешмалар (учреждениеләр) һәм предприятиеләр хезмәткәрләре һәм коллективлары бүләкләнә.

2. Дәүләт граждан хезмәткәрләре, Ветеринария идарәсе хезмәткәрләре, ведомствога караган дәүләт ветеринария учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре тармакта 5 елдан да ким булмаган эш стажы булганда вазифа йөкләмәләрен үрнәк башкарулары һәм мактауга лаеклы хезмәте өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләнәләр.

Дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Ветеринария идарәсе хезмәткәрләренә, ведомство карамагындагы дәүләт ветеринария учреждениеләре җитәкчесе һәм хезмәткәренә юбилей датасына ирешүләре: 50, 55, 60, 65 ел һ.б., аларны Мактау грамотасы белән утыртуга мөстәкыйль нигез булып тора.

3. Оешма (учреждение) һәм предприятиеләр коллективларын Мактау грамотасы белән бүләкләү өчен түбәндәге юбилей даталары билгеләнә: 20 ел һәм аннан соң һәр 5 ел саен.

4. Бүләкләү турында карар ветеринария идарәсе башлыгы тарафыннан кабул ителә.

5. Мактау грамотасы белән бүләкләү Ветеринария идарәсе боерыгы нигезендә үтенечнамә буенча башкарыла.

6. Бүләкләү турындагы үтенечнамә Ветеринария идарәсе башлыгы исеменә язма рәвештә кертелә:

- Ветеринария идарәсенең структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм ведомство буйсынуындагы дәүләт ветеринария учреждениеләре җитәкчеләренә карата башлыкның урынбасарлары;

- әлеге структур бүлекчәләрнең хезмәткәрләренә карата Ветеринария идарәсенең структур бүлекчәләре җитәкчеләре белән;

- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының ведомство буйсынуындагы дәүләт ветеринария учреждениеләре җитәкчеләре һәм аларның хезмәткәрләренә карата;

- Татарстан Республикасының башка министрлыклары һәм ведомстволары, оешмалар (учреждениеләр) һәм предприятиеләр җитәкчеләре.

7. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендә Ветеринария идарәсенең ведомство бүләге белән бүләкләүгә күрсәтмә кушылырга тиеш.

8. Ел дәвамында дисциплинар җәза алган затлар Мактау грамотасы белән бүләкләнергә тиеш түгел.

9. Мактау грамотасын тапшыру тантаналы шартларда Ветеринария идарәсе башлыгы яисә аның кушуы буенча бүләкләнүче эшли торган коллективта башка вазыйфаи затлар тарафыннан башкарыла.

10. Мактау грамотасы белән бүләкләнгән хезмәт кенәгәсенә тиешле язма кертелә.

11. Дәүләт яисә ведомство бүләге белән бүләкләнгән затлар Мактау грамотасы белән бүләкләүгә алдагы бүләкләүдән соң өч елдан да соңга калмыйча тапшырыла ала.

12. Мактау грамотасы югалган очракта аның дубликаты бирелми. Мактау грамотасы белән бүләкләү турында боерык югалган очракта, аның Ветеринария идарәсенең кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге раслаган күчермәсе бирелә.

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең
10.07.2015 № 286-к боерыгына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгының рәхмәт хаты турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгының Рәхмәт хаты (алга таба - Рәхмәт хаты) дәүләт граждан хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба - Ветеринария идарәсе) хезмәткәрләрен тармак үсешенә зур өлеш керткән өчен бүләкләү булып тора.

2. Рәхмәт хаты белән Ветеринария идарәсе карамагындагы дәүләт ветеринария учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре, Татарстан Республикасының башка министрлыклары һәм ведомстволары хезмәткәрләре, шулай ук идарәгә йөкләнгән бурычларны хәл итүдә ярдәм итүче оешмалар (учреждениеләр) һәм предприятиеләр хезмәткәрләре һәм коллективлары бүләкләнергә мөмкин.

3. Бүләкләү турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы тарафыннан кабул ителә.

4. Рәхмәт хаты белән бүләкләү Аетеринария идарәсе боерыгы нигезендә үтенечнамә буенча башкарыла.

5. Бүләкләү турындагы үтенечнамә Аетеринария идарәсе башлыгы исеменә язма рәвештә кертелә:

- Ветеринария идарәсенең структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм ведомство буйсынуындагы дәүләт ветеринария учреждениеләре җитәкчеләренә карата башлыкның урынбасарлары;

- әлеге структур бүлекчәләрнең хезмәткәрләренә карата Ветеринария идарәсенең структур бүлекчәләре җитәкчеләре белән;

- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының ведомство буйсынуындагы дәүләт ветеринария учреждениеләре җитәкчеләре һәм аларның хезмәткәрләренә карата;

- Татарстан Республикасының башка министрлыклары һәм ведомстволары, оешмалар (учреждениеләр) һәм предприятиеләр җитәкчеләре.

6. Рәхмәт хаты белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендә Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә күрсәтмә кушылырга тиеш.

7. Ел дәвамында дисциплинар җәза алган затлар Рәхмәт хаты белән бүләкләнмәскә тиеш.

8. Рәхмәт хаты бүләкләнүче коллективта җитәкче яки аның кушуы буенча башка вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырыла.

9. Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән хезмәт кенәгәсенә тиешле язма кертелә.

10. Рәхмәт хаты югалган очракта аның дубликаты бирелми. Боерык югалган очракта, Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында аның Ветеринария идарәсенең кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге раслаган күчермәсе бирелә.

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең
10.07.2015 № 286-к боерыгына
3 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ________________________________________________
2. Вазыйфасы, эш урыны ____________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(Структур бүлекчәнең, территориаль бүлекчәнең, дәүләт органаның, учреждениянең, ведомстваның тулы исемен күрсәтергә)

3. Туган көне _____________________________________________________________________
4. Белеме ________________________________________________________________________
5. Тәмамлады _____________________________________________________________________

(белем бирү учреждениесенең исеме, тәмамлану елы)

6. Белеме буенча белгечлек __________________________________________________________
5. Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме ___________________________________________________
6. Нинди дәүләт һәм ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән, дата ___________________________

___________________________________________________________________________

7. Гомуми эш стажы ____________________ Тармакта эш стажы __________________________

Әлеге коллективта эш стажы ___________________

9. Бүләкләнүченең аерым хезмәтләре күрсәтелгән Характеристика: __________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

10. ________________________ кандидатурасы хезмәт коллективы җыелышы яки Советы тарафыннан тәкъдим ителде __________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(территориаль орган, учреждениеләр, ведомстволар, оешмалар исеме)

___________________________________________________________________________

(фикер алышу датасы, беркетмә №)

11. Тәкъдим ителә ________________________________________________________

(бүләк төре)

Ветеринария идарәсенең структур бүлекчәсе,
министрлык, ведомстволар, оешмалар җитәкчесе

___________________________
(Имза)

___________________________
(Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең
10.07.2015 № 286-к боерыгына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең ведомство бүләге белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алу журналы

Сул як

| № п/п | Бүлекчәнең исеме | Бүләкләү формасы | |
|---|---|---|---|
| | | Дәүләти (Россия Федерациясенең/ Татарстан Республикасың Дәүләт бүләге) | Ведомствоның (Мактау грамотасы, Рәхмәт хаты) |

Уң як

| Бүләкләнүче | | Бүләкләү турында Документ | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| Ф.И.О. | Вазифа | Документ төре | № | Дата (кк.аа.ее.) | |